| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТИМЕРШЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| 422057, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Тимершик, ул. Пионерская, 19 а тел. (84362) 2-23-23 | | 422057, Татарстан Республикасы, Саба районы, Тимершык авылы, Пионер урамы, 19 а йорт тел. (84362) 2-23-23 |

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

| РЕШЕНИЕ 04.06.2021 | КАРАР №14 |
|---|---|

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү тәртибе турында 20.12.2012 елгы 29 номерлы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2020 елгы 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы 20.12.2012 елгы 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 10 пунктның 3 пунктчасының 2 абзацында " хезмәт кенәгәсеннән” сүзләреннән соң “һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/timershik адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Тимершык авыл җирлеге башлыгы А.Х. Хаҗиев